Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ

КАРАРЫ

10.06.2022 ел　　Менделеевск ш.　　№115

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының бүләкләү комиссиясе турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының бердәм бүләкләү сәясәтен булдыру һәм Менделеевск муниципаль районының социаль-икътисадый үсешенә зур өлеш керткән гражданнарны, хезмәт коллективларын һәм оешмаларны бүләкләү системасын камилләштерү, шулай ук һөнәри хезмәт эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында,

**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы**
**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының бүләкләү комиссиясе турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының законлылыкны, хокук тәртибен һәм кеше хокукларын саклау буенча даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе урынбасары　　Л.К.Галеева

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль
районы Советының
2022 елның 10 июнендзге
115 номерлы карарына
КУШЫМТА

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БҮЛӘКЛӘР БУЕНЧА КОМИССИЯСЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Менделеевск муниципаль районының бүләкләр буенча комиссиясе (алга таба - комиссия) гражданнарны Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре, Татарстан Республикасы бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итүгә һәм Менделеевск муниципаль районы бүләкләре (алга таба - муниципаль бүләкләр) белән бүләкләүгә бәйле мәсьәләләрне карау өчен, бүләкләр тапшыру һәм мактаулы исемнәр бирү өлкәсендә бердәм сәясәтне гамәлгә ашыру максатларында даими эшләүче консультатив орган булып тора

Комиссия иҗтимагый башлангычларда эшли.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары, башка федераль норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасы Конституциясе, республика законнары, республиканың башка норматив хокукый актлары, Менделеевск муниципаль районының хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

## 2. КОМИССИЯ ФУНКЦИЯЛӘРЕ

Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

2.1. Гражданнарның һәм оешмаларның Россия Федерациясенең дәүләт бүләкләре, Татарстан Республикасы бүләкләре белән бүләкләү һәм гражданнарны муниципаль бүләкләр белән бүләкләү турындагы тәкъдимнәре буенча мөрәҗәгатьләрен карый.

2.2. Бүләкләү турында комиссиягә кергән материалларның федераль һәм республика законнары, муниципаль районның муниципаль хокукый актлары таләпләренә туры килүен анализлый;

2.3. Менделеевск муниципаль районы башлыгына гражданнарны Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре, Татарстан Республикасы бүләкләре белән бүләкләүгә тапшыру мөмкинлеге, шулай ук гражданнарны муниципаль бүләкләр белән бүләкләү мөмкинлекләре турында бәяләмә тәкъдим итә.

2.4. Бүләкләүгә тәкъдим итү турындагы материалларны бәяли һәм Менделеевск муниципаль районы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы гражданнарны һәм оешмаларны бүләкләүгә , Россия Федерациясенең,

Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре, шулай ук муниципаль бүләкләр белән бүләкләүгә объектив якын килүне тәэмин итә.

## 3. КОМИССИЯНЕҢ ХОКУКЛАРЫ

Үзенә йөкләнгән вазыйфаларны башкару өчен комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

3.1. Менделеевск муниципаль районының, шәһәр һәм авыл җирлекләренең дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан үз функцияләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле материаллар һәм документлар соратып алырга;

3.2. Федераль һәм өлкә законнарында, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән очракта, бүләкләү турында кергән материалларны эшләп бетерүгә кире кайтару турында карар кабул итәргә;

3.3. Комиссия утырышларында Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Менделеевск муниципаль районы җирле үзидарә органнары, шәһәр һәм авыл җирлекләре, Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре, Татарстан Республикасы бүләкләре һәм муниципаль бүләкләр белән бүләкләүгә тәкъдим итүче оешмалар вәкилләрен, комиссиягә кергән бүләкләү турындагы тәкъдимнәр һәм материаллар нигезендә тыңларга

## 4. КОМИССИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ

4.1. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма документлар комиссиягә кергәннән соң 15 көннән дә соңга калмыйча уздырыла.

4.2. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының гомуми санының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия утырышларын комиссия рәисе үткәрә (ул булмаганда - комиссия рәисе урынбасары).

4.4. Комиссия утырышының көн тәртибе комиссия рәисе тарафыннан (ул булмаганда - комиссия рәисе урынбасары) раслана.

4.5. Комиссия карарлары утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, комиссия утырышында рәислек итүче тавыш хәлиткеч булып тора.

4.6. Комиссия карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа комиссия утырышында рәислек итүче һәм комиссия секретаре аны кабул иткән көннән соң өч көн эчендә имза сала.

4.7. Комиссия карары нигезендә гражданнарны Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре, Татарстан Республикасы бүләкләре белән бүләкләүгә тапшыру, муниципаль бүләкләр белән бүләкләү мөмкинлеге турында бәяләмәләр төзелә, алар комиссия рәисе тарафыннан имзалана һәм муниципаль район башлыгына җибәрелә.

4.8. Комиссия эшчәнлеген оештыруны Менделеевск муниципаль районы Советы аппараты тәэмин итә.

5. Комиссия составы

5.1. Комиссия составы Менделеевск муниципаль районы башлыгының карары белән раслана.